ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22 февраль, 2017 ел № 15/7

Хезмәткә түләүнең аерым сорауларын
җайга салу турында

2016 елның 3 июлендәге «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 347-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 24 декабрендәге «Уртача хезмәт хакын исәпләүнең үзенчәлекләре турында» 922 санлы Карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 10 декабрендәге «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 1339 санлы Карары, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең, җитәкче урынбасарларының, баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы һәм әлеге муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы (җитәкченең, җитәкче урынбасарының, баш бухгалтерның хезмәт хакын исәпкә алмыйча) нисбәтенең иң чик дәрәҗәсе бердән сигезгә кадәр билгеләнә.

Муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең, җитәкче урынбасарларының, баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы һәм әлеге муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләренең финанс тәэмин итү чыганаклары хисабына формалашучы уртача айлык хезмәт хакы нисбәте календарь ел өчен исәпләнә. Муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең, җитәкче урынбасарларының, баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы һәм муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы нисбәте тиешле җитәкченең, җитәкче урынбасарының, баш бухгалтерның уртача айлык хезмәт хакын әлеге муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакына бүлү юлы белән билгеләнә. Күрсәтелгән максатларда уртача айлык хезмәт хакын билгеләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 24 декабрендәге «Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре хакында» 922 санлы Карары белән

расланган Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында Нигезнамәгә таянып гамәлгә ашырыла.

2. Башкарма комитетның муниципаль учреждениеләр һәм (яки) муниципаль унитар предприятиеләр эшчәнлегенең тиешле юнәлешен координацияләүче вазифаи затлары хисап елыннан соң килүче елның 31 мартыннан да соңга калмыйча, муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының календарь ел өчен хисапланучы уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыралар.

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиешле мәгълүматта түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) муниципаль учреждениеләрнең, муниципаль унитар предприятиеләрнең тулы исеме;

2) җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының вазифасы;

3) календарь ел өчен хисапланучы уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат.

4. Әлеге Карарның 2 пункты белән каралган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиешле мәгълүмат составында әлеге Карарның 2 пунктында күрсәтелгән затларның яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка шәхси аралашу чараларын билгеләргә мөмкинлек бирүче, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яки конфиденциаль характерда булган мәълүматларны күрсәтү тыела.

5. Җитәкчеләр, җитәкче урынбасарлары һәм баш бухгалтерлар хезмәтенә түләү шартлары уртача айлык хезмәт хакы күләме нисбәтенең иң чик дәрәҗәсен исәпкә алмыйча билгеләнергә мөмкин булган муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр исемлеге Башкарма комитет карары белән раслана.

6. Әлеге Карар рәсми басылган көннән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме — Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ